УДК 821.512.145

*З.З. Рәмиев*

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ҺӘМ ФАТИХ ӘМИРХАН (1917 елга кадәр)

В статье сделана попытка раскрыть суть творческих взаимоотношений и взаимовлияния двух классиков татарской литературы – Фатиха Амирхана и Галимджана Ибрагимова. Показана реакция Г. Ибрагимова на опубликованные произведения Ф. Амирхана, эволюция его взглядов на творчество писателя.

**Ключевые слова:** Галимджан Ибрагимов, Фатих Амирхан, татарская литература начала XX века, татарская литературная среда начала XX века.

Теге яки бу әдип-язучының иҗат дөньясы, сәнгатьчә фикерләве турында сүз барганда, һәрвакыт диярлек аның чордаш каләмдәшләре белән бәйләнешләрен ачыклау зарурияте дә туа. Бу аңлашыла да, чөнки бер генә иҗатчы да япа-ялгыз мохиттә яшәми. Әлеге бәйләнеш, билгеле ки, төрле характерда була: кайсы – якыннан, кайсы – читтән торып, кайсы – бер яклы гына, кайсы – кара-каршы...

Күптән түгел басылып чыккан һәм татар филологиясе өчен уникаль фәнни хезмәттә – Габдулла Тукайның персональ әдәби энциклопедиясендә дә бу нәрсә күз алдында тотылган иде. Китап белән танышып өлгергән кешеләр күргәндер, анда Тукайның замандаш әдипләре белән галәкасе турында да тыгыз фикерле мәкаләләр урын алган, мәсәлән, «Әмирхан Фатих», «Ибраһимов Галимҗан», «Исхакый Гаяз», «Камал Галиәсгар» кебек мәкаләләр – шундыйлардан. Аларның авторлары чордаш әдипләрнең Тукайга шәхсән һәм басылып чыгып торган әсәрләренә, китапларына үзенчәлекле мөнәсәбәтләрен һәм, билгеле инде, шагыйребезнең дә каләмдәшләре иҗатына, үз-үзләрен тотышларына уңай яки тискәре карашын ышанычлы фактларга нигезләнеп тасвирларга омтылдылар.

Киләчәктә дә, мондый персональ (шәхси) энциклопедияләр төзелә калса, әдипләр арасындагы мөнәсәбәтләрне шәрехләү һәм укучыга җиткерү мәсьәләсе дә алга килеп басачак. Шуны истә тотып, мин андый хезмәтләрнең Фатих Әмирхан һәм Галимҗан Ибраһимовларга да багышланганнарын тудыру эшенә керештем, хәтта ки икесендә дә урын алырдай бер мәкалә язып карарга ниятләдем. Ул «Ибраһимов Галимҗан» дип тә, «Әмирхан Фатих» дип тә исемләнә ала, әмма эчтәлекләре исә тулысынча диярлек тәңгәлләшәчәк («Библиографик күрсәткеч»ләрендә композиция үзгәрә).

Бер үк чорларда яшәп иҗат иткән бу ике әдипнең реаль тормышта беренче мәртәбә очрашу-аралашуларына кагылышлы мәгълүматлар истәлекләрдә дә, матбугат битләрендә дә, хатларында да бик аз очрый. Ибраһи-

мовның 1936 елгы «Автобиография»сеннән күренгәнчә, ул Казанга 1909 елда (көзгә таба) университетка укырга керү нияте белән килеп чыга [Ибраһимов, т. 9, б. 54] (1912 елга кадәр яши, димәк ки, очрашу шул вакытларда гына була ала). Әмма аңа кадәр инде алар бер-берсен белгәннәр. 1907 елда Кавказда мөгаллим булып торган чагында Ибраһимов «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» исемле беренче хикәясен яза һәм кулъязма тиздән Ф. Әмирхан кулына килеп керә (әсәр авторы «Мөхәррирённән» дигән аңлатмасында: «Фатих Әмирханов җәнабләренең кулына төшеп...» – ди [Ибраһимов, т. 1, б. 504]). И. Нуруллин, әсәрнең кулъязмасын Г. Ибраһимов үзе Казанга килеп чыгып, «Әлислах»ка тәкъдим итә, дип яза [Нуруллин, б. 115] (Ф. Ибраһимова исә хикәягә язган комментарийда: «Әлислах» редакциясенә кулъязма сентябрь ахырында алына», – ди [Ибраһимов, т. 1, б. 504–505]). И. Нуруллин сүзе дөреслеккә туры килсә, очрашу 1907 елның сентябрь – октябрь башларында ук булыр иде. Чөнки газета редакциясендәге даими хезмәткәрләр, шул исәптән Г. Тукай да, хикәяне бастырырга теләмәсәләр дә, Ф. Әмирхан аны дөньяга чыгару фикерен яклый [Нуруллин, б. 115]. Әсәр газетаның 1907 елның 10 октябрь (2 нче) санынnan укучылар игътибарына тәкъдим ителә башлый (унҗиде санда чыга). «Хикәяне алып укыгач, Ф. Әмирхан, тәүге уңышы белән тәбрикләп, яшь авторга хат яза; аңа әдәби иҗат эшендә зур уңышлар тели, дусларча киңәшләр бирә; шунда ук яшь әдипкә газетаның Уфа губернасындагы хәбәрчесе булырга тәкъдим итә» (Ф. Ибраһимова сүзе [Ибраһимов, т. 1, б. 505]). Г. Ибраһимов бу тәкъдимне кабул итә. Газетаның 1908–1909 еллардагы саннарында аның сигез язмасы басылган. Язучының хатыны Г. Мөхәммәдова «Эзләнүләр» исемле китабында Ибраһимовның, кулъязманы «Әлислах» редакциясенә тапшыру өчен, 1907 елда «көзнең соңгы бер көнендә» Казанга махсус килеп чыгуын, ләкин анда Ф. Әмирханны очратмавын, ике сәгатьтән пристаньнан кузгала торган пароход белән кире Уфага китеп баруын яза [Мөхәммәдева, б. 190].

1908–1915 еллар – Г. Ибраһимовның прозада, ә Ф. Әмирханның исә прозада һәм драмада актив иҗат иткән вакытлары. Билгеле ки, алар бер-берсенең язганнары белән эледән-эле «очрашып» торганнар (китаплары басылган, вакытлы матбугат битләрендә еш чыгыш ясаганнар). 1910 ел башында Г. Ибраһимов, татар шагыйре дигәч тә, укучы зиһенендә Тукаев пәйда була, дип яза [Ибраһимов, т. 5, б. 7], ә «Татар кызы»н асаре шигъриягә (чәчмә белән язылган шигъри әсәрләр рәтенә) кертеп, «Татар матбугаты» исемле мәкаләсендә бу вакытларда хикәячелек мәйданында алгы урынны биләүче итеп нәкъ менә Ф. Әмирханны күрсәтә. Шул ук вакытта «үзенең бөтен тәнкыйтьләрен реальный ноктадан йөрткән бу әфәнде» хыялга корылган (яисә хыял һәм хакыйкать катыш) әсәрләр язуга авыша дип саный, моның

сәбәпләре итеп «иске татар тормышын белмәүне, шәхси «тормыш рәвеше тәэсире»н күрсәтә, каләменең шигърияте исә Г. Исхакыйныкыннан яктырак дип тәкуя [Татар матбугаты]. 1901 елның 22 январенда Ф. Әмирханга Томскидан җибәргән хатында И. Бикколов та: «Габдинең сезнең тугрыдагы заметкасы бик тугры. Сез үзегез реализмнан ераграк йөрисез», – ди, Ф. Әмирханның «Танымаганнан таныштык» хикәясендәге Разия, студент Мортазин образларын «реальный түгел» дип, ә Гайсаны исә нәкъ татар байбәтчәсе итеп саный [Ибраһим Бикколов хатлары, б. 164]. Ике кешенең шактый охшаш бәя бирүләрен Ф. Әмирхан игътибарсыз калдырмаган шикелле, чөнки И. Бикколов 18 көн соңра язган хатында бу мәсьәләгә кабат кагыла, аныңча, Гайса образы шактый дәрәҗәдә тормыштан алынган (әсәрне «бөтенләй алай бушка чыгарып булмый» [Ибраһим Бикколов хатлары, б. 167]; Ф. Әмирхан хаты сакланмаган). Г. Ибраһимов, шул ук елгы «Әдәбият мәсьәләләре» исемле шактый күләмле язмасында төрек әдәбиятын күзаллаганда хәтергә Әхмәд Мидхәд, Мәхмүд Әсгадь, Тәүфикъ Фикрәтләрне килүен искәртеп, татар әдәбияты әһелләре арасында беренчеләр итеп нәкъ менә Тукай һәм Әмирхан исемнәрен атый [Ибраһимов, т. 5, б. 21].

Г. Ибраһимов – каләмдәшенең «Хәят» һәм «Урталыкта» әсәрләренә башлап сүз әйтүчеләрдән дә. Шул заман проза әсәрләрендәге җитди кимчелекләрне (һаман саен муллаларга тию, шәкерт тормышын, хәлфәләрне, мәдрәсәләрне яманлау, татар хатынының зарлы язмышын тасвирлау) күрсәтеп, ул «Хәят» повестеның басылып чыгуын бик урынлы күрә, анда «җиңеллек, каләм осталыгы, бәйрәм, яшьлек вә шатлык хис кыйлын»уын әйтә, гомумән, әдәбият мәйданындагы вакыйгага тиңли. Әмма, аның фикеренчә, әсәрдә «сай чыккан җирләр дә күп»: яшьләрнең беренче мәхәббәте дә сыек чыккан, Хәят тибының табигыйлыгы шөбһәле (И. Нуруллин фикеренчә, Ибраһимов Хәятне типик образ итеп карый алмый); «милли хикәя» диелсә дә, анда «миллилек» җитми: теманың үзәгендә «татарлык аңкып торырга, каһарманнар татар рухы илә мөкәммәл рәвештә сугарылган булырга кирәк» [Ибраһимов, т. 5, б. 57–59] (хәзерге заманда да бик актуаль таләп!). Шул ук вакытта Ибраһимов әсәрнең беренче кисәге генә нәшер ителгәнлеген дә онытмый, әдәби кыйммәте турындагы фикерен икенче кисәге чыккач әйтәчәген искәртә. «Урталыкта» романына бәя бирүне дә Ибраһимов соңгарак калдыра, чөнки «урта кулда мең битләр чамасы булуы ... гөман ителгән» [Ибраһимов, б. 57–58]; әле беренче кисәге генә басылып чыккан (икенче кисәге бераз соңрак – шул ук 1912 елның ахырында чыга). Аныңча, әсәрнең теле ачык, «ләкин бераз ясалмарак татарчага якын», эчтәлегендә төп урынны укучы яшьләр һәм туташлар тормышы били. Авторның бу чорда, гомумән, роман жанрына биргән бәяләмәсе дә дикъкатькә лаек: ул үзенең бөтен

тәмамы вә бөтен торышы белән аерым, билгеле һәм бөтен бер мәгънәне күрсәтергә тиеш.

Г. Ибраһимовның каләмдәше әсәрләренә тәнкыйди фикерләр дә әйтүе ике әдип арасындагы мөнәсәбәтләргә сизелерлек тәэсир-йогынты ясамаган булса кирәк. Мәсәлән, бу Ф. Әмирханның Ибраһимовка 1912 елның көзендә Киевкә китәр алдыннан тиздән чыга башлаячак «Аң» журналында язышырга рәсми рәвештә мөрәҗәгать итүендә күренә. Ләкин журналның 1912 елның 15 декабрендә басылган беренче номеры, 1913 елның 3 январенда Х. Кайбышевка юллаган хатыннан аңлашылганча [Ибраһимов, т. 9, б. 69–70], ни сәбәпледер, бу вакытка кадәр Ибраһимов кулына килеп керми. Әлеге фактны Әмирханның (һәм нашир Ә. Хәсәнинең дә) мәгънәсезлеге итеп бәяләсә дә, ул, Киев вакыйгаларыннан исәнимин котылгач, аларның чакыруын истә тотып, Казанга килеп чыга (1913 ел, 16 сентябрь) һәм «Аң» журналының сәркатибе вазифасын ала; журнал 21 нче саныннан аның карамагында чыга башлый (бу санда Ф. Әмирханның «Корбан» хикәясе дә бар). Әлеге хатта Ибраһимов Әмирханның «Халык кызлары» исемле әсәрен ошатмавын да белдерә: аның Айга менгән Зөһрә турында язарга алынганлыгына баштарак ачуы килгән булса, әсәрне күргәч, ачуы инде таралуы, хәтта авторны кызгануын хәбәр итә («бик озаклап көлә»). Ул «халык кызлары» Айсылу (Зөһрә) турында Х. Кайбышев һәм Зөлхәбирә турында «бичара» З. Бәшири язган хикәяләрне Ф. Әмирханның «Халык кызлары» китабындагы текстларыннан югарырак куя, үзенең Сөембикә турында башкачарак язарга уйлавын да әйтеп уза. 1913 елда гына басылып чыккан китапның ахыргы битендә текстның 1912 елның сентябрендә үк язып тәмамлануы әйтелгән, димәк, Әмирханның яисә нәшрияттә эшләүчеләрнең рөхсәте беләндер, Г. Ибраһимов Казанда чакта ук әсәр тексты белән танышкан була. Хат ахырында «бер минутлык тәэсир астында, гайре табигый халәттә языла. Эчендә җүләрлекләре булса, шул халәттән күрерсез» диюеннән, Ибраһимовның андагы үз фикерләре гаять субъектив икәнлеген тануы сизелә. Әдип, аңга килеп дияргәме, соңрак, 1914 елда, «Яңа әдәбият» исемле хрестоматиясен төзегәндә, Ф. Әмирханның «Искергән баһадир» исемле парчасы белән бергә, әлеге «Халык кызлары» эчендәге «Ай өстендәге Зөһрә кыз»ны – «әкият вә тарихлардан алынып язылган хикәя»сен дә урнаштырган, аны «әдәби мәҗмуганың кадерле урынын зиннәтләрлек парчалар»ның берсе итеп бәяләгән [Ибраһимов, т. 5, б. 171]. Шул ук елгы «Матбугат вә әдәбиятымызның барышы» исемле еллык хисабында, Ф. Әмирханны да телгә алып, ул әдипнең 1913 елда аз язуын, «әдәбияттан бигрәк журналистикага бирелеп» баруын әйтә. Аның фикеренчә, әлеге «Халык кызлары» «матур вә милли мәүзугъны җиңел вә мәгънәле бер эслүб илә ифадәдән гыйбарәт» [Әмирхан, т. 3, б. 16]. М. Хәсәнов «Галимҗан

Ибраһимов» исемле монографиясендә 1914 елның февралендә Казанда уздырыласы яшьләр җыелышында әдип «Татар яшьләренең бурычлары» дигән доклад ясарга алынганын яза. Җыелышка Ф. Әмирхан да чакырылган була [Хәсәнов, б. 83].

Г. Ибраһимов Ф. Әмирханның XX гасыр башы татар прозасы казанышы булырдай әсәрләр иҗат итүен таныган, үзе романтик хис-кичерешләргә, тасвирларга зур урын биргән булса да, каләмдәше әсәрләренең реалистик эчтәлекле булуын теләгән. Ә менә ул заман матбугаты битләрендә, хатларында, истәлекләрдә ике әдипнең якыннан аралашып яшәүләре хакында мәгълүматлар бик аз. Монда икесенең дә холык-фигыльләрендәге үзенчәлекләр роль уйнаган шикелле. Фактлар Яңа Бистәдә туып үскән Ф. Әмирханның, аяксыз хәлдә дә, шәһәр атмосферасында үзен иркен тотуы, төрле мәдәни чараларда бик теләп катнашуы, зыялы кешеләр, яшьләр белән очрашырга, уен-көлке сөйләшергә дә яратканлыгы турында сөйли. Г. Ибраһимов исә Казанда вакыт-вакыт кына яшәп ала, ул – чит җирдән – башкорт тарафыннан килгән чит кеше; матди тормышын да тәэмин итү өчен иҗат эше белән аеруча актив шөгыльләнергә кирәк булгандыр. Икенче бер нәрсә дә мәгълүм: 1910 ел башында «Хәзер шигырь мәйданында иң шәүкәтле һәм иң галәбәле рольне мөхтәрәм Тукаев уйный» дип язып чыккан Г. Ибраһимовның шагыйрь иҗатын бәяләве бераздан башка төс ала. Тукай вафаты көннәрендә басылган «Татар шагыйрьләре» исемле җитди хезмәтендә ул хәтта аның шагыйрьлеген шөбһә астына ала. Ә 1908 елдан Тукай белән «мәхрәм» (сер яшерми торган) дуслар булып [Әмирхан, т. 4, б. 119] киткән, аны татарларның «иң мәшһүр, иң сөекле шагыйре» итеп күргән Әмирхан Г. Ибраһимов белән шагыйрь арасындагы мөнәсәбәтләрдә матурлык булмаганын күреп, сизеп торган һәм мондый бәя белән килешмәгән булырга тиешле...

Ике әдип тә 1917 елгы Февраль революциясен рухланып каршы ала: Г. Ибраһимов беренче публицистик мәкаләсен («Куәт – халыкта») «Тәхет җимерелде. Богаулар өзелде...» дип башлап җибәрсә [Ибраһимов, т. 6, б. 115], Ф. Әмирханныкы исә «Богаулар өзелделәр» дип исемләнгән дә [Әмирхан, т. 3, б. 324]. Икесе дә Октябрьне кабул итә, 1917 елдан сул эсерлар партиясендә булган Г. Ибраһимов бераздан большевиклар партиясенә дә керә. Гражданнар сугышы елларында икесе дә вакытлы матбугатта большевиклар хакимиятен хуплап чыгыш ясыйлар. Илдә тынычлык урнашты дип торганда гына Идел буенда килеп чыккан фаҗигале ачлык күренешләре дә аларны бик нык борчый. Бу Г. Ибраһимовның совет чорындагы басмаларыннан читләштерелгән «Адәмнәр» повестенда, Ф. Әмирханның көндәлекләрендә (дүрттомлы «Әсәрләр»ендә кыскартылып кына урнаштырылды) чагылыш тапкан. Яңа чынбарлыкта алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең кайбер мөһим яклары соңгы елларда Н. Вәлиев,

М. Әхмәтҗанов кебек галимнәрнең китап һәм мәкаләләрендә күрсәтелде. Аларны тәфсилләп өйрәнү, хакыйкатьтә барынча ачыклау киләчәк эше булып кала.

**Әдәбият**


Аң. 1912. № 1.

Аң. 1914. № 1.

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 3 т. 512 б.

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 4 т. 390 б.

Ибраһим Бикколов хатлары // Духовное наследие: поиски и открытия. Казань: ИЯЛИ, 2016. Вып. 2. С. 164–169.

*Ибраһимов Г.* Әсәрлә: 9 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 1 т. 510 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 9 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 т. 616 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 9 томда. Казан: Татар. кит. нәшр, 1986. 6 т. 606 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 9 томда. Казан: Фикер, 2000. 9 т. 464 б.

*Мөхәммәдева Г.* Эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 376 б.

*Нуруллин И.* Фатих Әмирхан. Атаклы кешеләр тормышыннан. Казан: Татар. кит. нәшр.,1988. 279 б.

Татар матбугаты // Йолдыз. 1910. 12 январь.

*Хәсәнов М.* Галимҗан Ибраһимов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. 332 б.



***Рәмиев Зөфәр Зәйни улы,***

*филология фәннәре докторы,*

*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре*